**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус сакланыла торган табигать территорияләреннән тыш, ауның параметрларына үзгәрешләр кертү турында**

Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуны камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус сакланыла торган табигать территорияләреннән тыш, ауның параметрларын билгеләү турында» 2013 елның 12 апрелендәге ПУ-303 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1216 номерлы, 2014 елның 12 июнендәге ПУ-572 номерлы, 2015 елның 23 апрелендәге ПУ-412 номерлы, 2015 елның 16 июлендәге ПУ-654 номерлы, 2015 елның 15 августындагы ПУ-724 номерлы, 2016 елның 10 февралендәге ПУ-131 номерлы һәм 2016 елның 9 июлендәге ПУ-588 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус сакланыла торган табигать территорияләреннән тыш, ау параметрларының III кисәгенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 7-8 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. 2017 елгы җәйге-көзге-кышкы ау сезоны һәм 2018 елгы язгы ау сезоны чорына Татарстан Республикасының барлык аучылык биләмәләрендә суерга һәвәскәрләр һәм спорт авы тыела.

8. «Бөгелмә», «Забава», «Караеш», «Никольское» «Питрәч», «Поповское», «Юкә», Баулы һәм Бөгелмә районнарындагы ачык ау биләмәләреннән тыш, 2017 елгы җәйге-көзге-кышкы ау сезоны һәм 2018 елгы язгы ау сезоны чорына Татарстан Республикасының барлык аучылык биләмәләрендә көртлеккә һәвәскәрләр һәм спорт авы тыела.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 9-10 пунктлар өстәргә:

«9. «Ак Барс», «Актаныш», «Әлки», «Арча», «Баграж», «Бакчасарай», «Балтач», «Идел-Кама», «Дубрава», «Егерь», «Алабуга», «Зәй», «Зүзәй», «Игимский бор», «Кама яры», «Камское Раздолье», «Карамалы», «Кызыл юл», «Красный Бор», «Красновидово», «Лебяжье» (Минзәлә районы), «Лебяжье» (Чирмешән районы), «Менделеевск», «Минзәлә», «Мөслим», «Яңа Минзәлә», «Охотник», «Радуга», «Балык Бистәсе», «Рысь», «Сарман»,

«Свиногорье», «Төньяк», «Сухаревский», «Төги», «Төрнәс», «Укыту-тәҗрибә Саба урман хуҗалыгы», «Урахча», «Үрнәк», «Усы», «Чаллы», «Чирмешән», «Шереметьев», «Чишмә», «Шора», «Көньяк», «Янтык» аучылык хуҗалыкларында, шулай ук Әгерҗе, Алабуга, Лениногорск, Мөслим, Түбән Кама, Яңа Чишмә, Нурлат, Балык Бистәсе, Сарман, Тукай һәм Чирмешән муниципаль районнарының ачык аучылык биләмәләрендә соры көртлеккә һәвәскәрләр һәм спорт авы тыела.

10. 2017/2018 еллардагы ау чорында «Аксубай», «Актаныш», «Арча», «Баграж», «Барс», «Бөркет», «Бутино-Чишмә», «Идел», «Идел-Кама», «Дубрава», «Алабуга», «Зәй», «Игимский бор», «Кайбыч», «Кама-Исмәгыйль», «Камское раздолье», «Карамалы», «Кызыл Юл», «Красновидово», «Ласка», «Лебяжье» (Минзәлә районы), «Менделеевск», «Минзәлә», «Яңа Минзәлә», «Охотник», «Радуга», «Рысь», «Сарман», «Свиногорье», «Төньяк», «Сухарево», «Тархан», «Тәтеш», «Төги», «Үрнәк», «Шереметьево», «Чишмә», «Шора», «Ямаш», «Янтык» аучылык хуҗалыкларыннан һәм Аксубай, Әлмәт, Алабуга, Кайбыч, Лениногорск, Түбән Кама, Яңа Чишмә, Сарман, Тәтеш муниципаль районнарының ачык аучылык биләмәләреннән башка барлык аучылык биләмәләрендә соры куянга һәвәскәрләр һәм спорт авы тыела»;

в) 9 нчы пунктны 11нче пункт дип санарга.

2. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2017 ел, 07 июль
№ ПУ-608